СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

НУРЛАТ РАЙОНЫ ИЖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА НУРЛАТСКОГО РАЙОНА.

4 сентябрь, 1998 ел.
ҖОМГА

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 100 (8257) | Бәясе билгеләнгәнчә

## МӘКТӘПЛӘРДӘ ТӘҮГЕ КЫҢГЫРАУ



# «НУРЛАТТА ИҖАДИ ХЕЗМӘТТӘ ЯШИЛӘР»

***1нче сентябрь көнне Нурлат районында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х.Мөхәмматшин булып китте.***



Мәртәбәле кунакның район белән танышуы яңа оештырылган "Өмет" агрофирмасыннан башланды. Делегация Урта Камышлы авылының социаль үзгәрешләре белән танышты, аннан "Агрокультура" кооперативында чыгымга каршы механизм ныгыган дуңгыз һәм сыерлар фермасын карады. 300 баш дуңгызны өч пенсионер карый, бернинди механизм кулланылмый, электр энергиясе түгелми - бары 1 лампочка яна һәм... тәүлеккә 400 граммнан артык артым алына. Мондый аз чыгымлы ысул күршедәге сыер фермасында да, "Киекле" КХАсында да үзен күптән аклады инде. Соңгысында Фәрит Хәйруллович сыерларны "Альфа - лаваль" җайланмасы белән саву залын карады, шуңа охшаш саву җайланмасын үзебездә эшләү идеясен хуплады. Аннан ул шунда ук куелган сөт пастеризацияләү һәм аны тутыру җайланмасы белән танышты, аның хуҗалыкка китерәчәк икъисадый отышы белән кызыксынды.

"Терлекчелектә революция бара" - Фәрит Хәйруллович үз күзе белән күргән яңалыкларны шулай бәяләде.

Көндезге сәгать 12дә Ф.Х.Мөхәмматшин шәһәрдә сәнгать мәктәбе ачу тантанасында катнашты. Бу мәһабәт сәнгать сарае - Югары Советка депутатыбыз Фәрит Хәйрулловичның зур матди булышлыгы, ныклы контроле ярдәмендә торгызылган бина, шуңа да тантанада мәртәбәле кунак адресына эчкерсез рәхмәт сүзләре күп яңгырады. Фәрит Хәйруллович үз чыгышында Татарстан Республикасында мәгариф өлкәсенең зур яңарышлар кичерүе, аның базасы үсүенә мисаллар китерде, иң кыен икътисадый шартларны да түземлелек белән кичерә белгән укытучыларга рәхмәт белдерде. Ул сәнгать мәктәбен төзүдә район хакимияте башлыгы Ф.С. Сибагатуллинның шәхси өлешен югары бәяләде, мәктәп директорының үҗәтлеген мактап телгә алды, төзүчеләр адресына җылы сүзләр юллады һәм шундый зур хезмәт нәтиҗәсендә төзелгән бинада балаларга бай рухи башлангыч салыныр, дип ышаныч белдерде.

- Нурлат районы һәм нурлатлылар зур иҗади хезмәттә яшиләр,- диде Фәрит Хәйруллович һәм район, шәһәр халкына ары таба да шундый рух, омтылыш белән яшәүләрен теләде.

Аннан делегация "Кондырча" КХАсының нәселле атлар фермасында булды, район хакименең акыллы маллар турында илһамланып сөйләвен тыңлады.

Аннары иптәш Мөхәмматшин район икътисадында мөһим роль уйнаячак җитештерү объектлары - "Тәрнәс спирт заводы" дәүләт унитар предприятиесенә һәм Зүзәй нефть һәм газ чыгару промыселына юнәлде. Беренчесендә "Татспиртпром" производство берләшмәсе генераль директоры Р.Р. Шәйхетдинов белән берлектә заводта реконструкция барышын карадылар. Чиста спирт җитештереләчәк заводта барлык инженерлык эшләрен комплекста алып бару, социаль пландагы мәсьәләләрне дә соңгы чиккә калдырмау турында сүз булды. Тәүлеккә 20 тонна спирт җитештерәчәк заводны эшкә җибәрү вакыты итеп октябрь ахыры билгеләнде. "Димәк, 30 октябрьдә мин сездән телефон шалтыравы көтәм",- диде Фәрит Хәйруллович һәм аракы ясау линияләрен көйләүне дә суздмаска чакырды.



Зүзәй промыселында аны нефть эшкәртү заводы кызыксындырды. "Татнефтепром" берләшмәсе генераль директоры Р.К.Зарипов финанс кыенлыклары сәбәпле заводны җибәрү срогы бер кичектерелүен әйтте, хәзер дә матди кыенлыклар кичерүләрен яшермәде. Ә продукция - битум, мазут, дизель ягулыгы - һәммәсе бик кирәкле нәрсәләр бит! Иптәш Мөхәмматшин заводны җиһазлап бетерү өчен кирәкле сумма - 4 млн. сумны табарга булышырга вәгъдә бирде. Визит ахырында Фәрит Хәйруллович район белән танышудан алган тәэсирләре белән уртаклашты.


- Районда күп эшләр башкарыла, су белән тәэмин итү, газлаштыру, социаль үсеш объектлары төзү киң колачта бара. Зүзәй нефть эшкәртү заводына ярдәм итәргә кирәк дип саныйбыз, аннан продукция алынырга, республика, районга керем керергә тиеш. Авыл хуҗалыгында зур үзгәрешләр бара, киләсе ел уңышына ныклы нигез салына - гомумән, район киләчәккә карап яши.

Фәрит Хәйруллович белем көне уңаеннан педагоглар адресына теләкләрен дә җиткерде.

Ә саубуллашканда Нурлат районы сайлаучыларына сүз әйтүен үтендек.

- Мин алар каршында зур җаваплылык тоям. Нурлатлылар мине вак үтенеч - хатлар белән борчымыйлар, зур ниятләр, мактаулы эшләр белән яшиләр. Һәр очрашуыбызда мин аларга рәхмәтле калам,- дип Фәрит Хәйруллович якташларыбызга эчкерсез теләкләрен юллады.

**С.ХӘЙРУЛЛИНА.**



**Рәсемнәрдә:**
**Делегация "Киекле" КХАсының сөт пастеризацияләү цехында, Зүзәй нефть эшкәртү һәм Тәрнәс спирт заводларында.**

**Н.АЗИЗОВ фотолары.**

## ШАТЛЫКНЫ БҮЛЕШСӘҢ - УЛ АРТА

***Быелгы 1нче сентябрь көне Кизләү мәктәбе өчен аеруча истәлекле булды. Ничәмә дистә еллар дәвамында замана мәктәбен сыендырган мәдрәсә бинасы бу җәйдән соң үзенең нәни хуҗаларын әр - яңа кыяфәттә каршы алды. Район хакимиятенең махсус кайгыртуы һәм таләбе нәтиҗәсендә бу бинада быел капиталь ремонт үткәрелде. 547нче ПМК осталары быел яздан башлап 31 август төненә кадәр гаять зур күләмдә эш башкардылар. Мәктәпнең укытучылар коллективы да үзенең көтеп алынган җәйге ялы белән исәпләшмәстән, төзүчеләрнең хезмәтен тизләтү бәрабәренә алны - ялны белми эшләде.***

Менә ул заманча яңартылган борынгы бина! Менә ул әби - бабайлар тарафыннан олылап телгә алынучы изге нигез! Ә болары - шушы ояның кошчыклары - эреле - ваклы укучылар. Быелгы ел Кизләү өчен уңышлы ел булыр кебек. Бүген беренче класска килгән 12 сабый - авылның өметле киләчәгенә ишарә булсын берүк! Ишек алдында янәшәдә генә күтәрелеп килүче әр - яңа спорт залы да, мәктәп каршындагы иске агач йорт һәм киләчәккә булган планнар - хыяллар да - һәммәсе дә үз урынында. Алар бер - берсенә комачауламыйлар, киресенчә, яшәешнең тулы бер бөтен буларак кыйммәтен раслап торалар. Әнә ул иске агач йорт - кайчандыр борынгы мәдрәсәнең аерылгысыз юлдашы - авыл халкын һәм яшьләрне иманга өндәп, кыйбласын дөресләп торган мәчет булган. Аны сүтәргә бирәүнең дә кулы күтәрелмәве - халыкның рухи чисталыгын, изгелеккә табынуын күрсәтүче дәлил түгелмени? Киләчәктә бу йортның теләүчеләргә өстәмә гыйлем биреп, асылыбызга кайту юлында бер якты нур булып торуына өмет баглыйлар өлкәннәр.

Бүгенге 1нче сентябрь - мәктәп коллективы һәм әти - әниләр өчен дә үзенчәлекле. Аларның бәйрәм шатлыгын, мәктәпне яңарту шатлыгын уртаклашырга районның хакимият башлыгы Ф.С.Сибагатуллин үзе килгән иде. Онықларын җитәкләп килгән әбиләр дә, юк вакытын бар итеп мәктәпкә сугылган әти - әниләр дә, мәктәп коллективы үзе дә бу игътибарны бәяләп кабул итте. (Бу мәктәпне тәмамлаучылар, аллага шөкер, хакимият башлыгы да, шәһәр түрәләре дә булып эшләделәр. Әмма мәктәп мәшәкатьләрен барлап - кайгыртып, бәйрәмдә җылы сүз әйтү нияте белән килгәннәре генә булмады...)

**(Ахыры 2нче биттә).**

## БАР ХАЛЫК БӘЙРӘМ ИТТЕ

***Татарстан Республикасы мөстәкыйльлеге көне Нурлатта халык бәйрәме итеп билгеләп үтелде.***

Шәһәрнең үзәк мәйданы бәйрәм төсендә бизәлгән, сәүдә рәтләреннән шашлык исләре аңкый. Район хакимияте башлыгы урынбасары Н.Х.Абдуллин шәһәрлеләрне ТРның мөстәкыйльлек көне белән котлады, аның тарихи әһәмиятенә тукталды, суверен республика бәйрәменең Нурлат районының күпмилләтле халкы өчен уртак бәйрәм булуын әйтте.

Бу көн чыннан да бәйрәм төсе алды. Ораторлардан соң сәхнәгә күтәрелгән яшь парлар - Нурлаттан Евдокимовлар, Федотовлар, Салдакайдан Галанцевлар өчен ул аеруча истә калырлык булыр. Яңа гаилә коручыларга икеләтә бәйрәм истәлеге итеп бүләкләр тапшырылды. Аннан бу көнне - Галиев Илгиз һәм Лилияләрнең (4 кг. 400 граммлы!) тәүге уллары туу сөенече яңгырады. Ата кеше улы өчен бирелгән уенчыкның тарихын һичшиксез сабыена сөйләми калмас әле.

Бәйрәм сәхнәсен үзешчән артистлар алыштырды. Җыр - шигырьләр яңгырады, дәртле биюдә кызлар бөтерелде. Янәшәдә спорт уеннары - төрле ярышлар барды, нурлатлылар шашка - шахмат уеннарында, гер күтәрү, кул көрәше һ.б.да көч сынаштылар.

Бәйрәм дискотека белән тәмамланды. Яңгыр сибәләүгә карамастан, сәгать 10га кадәр мәйданда биюләр дәвам итте, халыкны яхшы кәеф ташламады.

## БЕЗНЕҢ АТЛАР КАЗАНДА ДА ҖИТЕЗ

***Республиканың суверенлыгы көне уңаеннан Казанда үткәрелгән ат чабышларында чиста нәселле атлар арасында безнең чаптарлар һич тә сынатмады. Узышта Президентыбыз үз иткән Ледок һәм хакимият башлыгының Альби атлары (җайдаклары Р.Цабов) җиңүче булдылар.***

# МӘКТӘПЛӘРДӘ ТӘҮГЕ КЫҢГЫРАУ

## ШАТЛЫКНЫ БҮЛЕШСӘҢ - УЛ АРТА

*(Ахыры. Башы 1нче биттә).*

Фатих Сәүбәнович тантанада катнашучыларны якты бәйрәм белән котлап, мәктәпнең киләчәгенә тукталды, авылның борынгылыгына бәйле рәвештә, район җитәкчелегенең олуг юбилей үткәрүгә дә уңай нияттә булуын белдерде.

Шатлыкны бүлешсәң - ул арта, кайгыны бүлешсәң - ул кими, дип юкка гына әйтмиләр. Бүгенге бәйрәм шатлыгын бүлешүчеләр - шушы мәктәпнең 1966 елгы чыгарылыш укучысы, ә бүген районның хакимият башлыгы урынбасары Н.Х.Абдуллин, район мәгариф бүлеге мөдире Г.М.Юнысов, җирле үзидарә рәисе Й.Х.Садыйков, "Киекле" хуҗалыгы җитәкчесе Н.Ш. Шәрәпов, мәгариф ветераннары, әти - әниләр һәм башка кунаклар - һәммәсе сүзнең дә, бүләкләрнең дә иң тансыгын сайлаганнар иде. Хуҗалыкта акча кытлыгына карамастан, җәй көне аеруча тырышып эшләгән укучыларны бүләкләү җаен тапканнар- иң уңганнарга берәр сарык, кайберләренә унар килограмм шикәр комы бирергә карар чыгарганнар. Хуҗалыкның мәктәпкә телевизор һәм видеомагнитофон бүләк итүе шулай ук зур сөенеч булды. Мәктәп хуҗалары да уңган төзүчеләргә рәхмәтләрен белдереп, истәлек бүләкләре тапшырдылар.

Җыр - музыка, шигъри багышлаулар белән үрелеп барган бәйрәмдә иң кечеләр - беренчеләр өчен яңгыраган кыңгырау чыңы ел дәвамында һәркемгә бәхет һәм шатлык китерсен иде.

**К.ҖАМАЛЕТДИНОВА.**



**Шәһәрнең 1 нче мәктәбендә** яңа уку елы икеләтә истәлекле булды - шәһәрнең иң өлкән урта мәктәпләреннән булган бу белем йорты быел 35 нче уку елын башлап җибәрде. Укучыларны һәм укытучыларны, ата - аналарны һәм кунакларны шушы тантана белән котлап, мәктәп директоры Ф.И.Гайнуллин быел мәктәпнең 52 классында 1208 бала белем алачагын, тагын 94енең балалар бакчаларындагы группаларда укытыласын әйтеп үтте. Җитәкче мәктәпнең былтыргы уку елында горурланырлык нәтиҗәләргә ирешүен дә телгә алып үтте: 100 егет һәм кызның 14е мәктәпне медаль алып тәмамлаган, 38 кеше югары, 34е махсус урта уку йортларына кергән. Мәктәп укучыларының бу данны киләчәктә дә ишәйтәчәкләренә шикләнмиләр. Мәктәпнең яңа уку елына үрнәк төстә әзерләнүе, шушы ярышта районда беренчелекне алуы үзе генә дә күп нәрсә турында сөйли. Мәктәп директоры бу эштә зур булышлык күрсәткән ит комбинаты, нефтебаза, агач склады, санэпидкүзәтү үзәге җитәкчеләренә, класс бүлмәләрен тәртипкә китерүдә якыннан катнашкан ата - аналарга ихлас рәхмәт белдерде. Мәктәпнең тәҗрибәле педагоглар сафына тагын сигез яшь укытучы кушылуы да белем һәм тәрбия бирү эшендә яңа рух өстәр дип ышаналар. Тантанада чыгыш ясаучылар, шул исәптән район һәм шәһәр хакимияте башлыгының Нурлат буенча урынбасары Р.Г.Билалов та укучыларга һәм мәктәп коллективына белем илендә яңадан - яңа уңышлар теләделәр.

Кыскасы, ул көнне беренчеләрне гомерләрендә тәүге тапкыр дәрескә дәшеп, унберенчеләргә белем нигезләрен үзләштерү юлында тагын бер хәлиткеч уку елы башлануын белгертеп яңгыраган кыңгырау чыңы алга таба да изгелеккә һәм игелеккә дәшеп торсын диясе килә.

**Р. МУЛЛИН**

1 сентябрьне Белем көне дибез. Анысы шулай. Ә авылда, җиргә берегеп, кырда һәм мал - туар арасында мәш килеп үскән балалар өчен каникул чорындагы хезмәтләренә йомгак ясау көне дә ул. Менә шуңа да Түбән Чаллы урта мәктәбендә узган тантаналы линейкада Синдряков исемендәге хуҗалык рәисе В.М.Абдрәхимов балаларны һәм укытучыларны яңа уку елы башлану белән җылы котлап, җәен олыларга зур булышлык күрсәткән укучыларга истәлекле бүләкләр дә тапшырды. Нинди генә эшләрдә эшләмәделәр өлкән класс укучылары бу җәйдә - терлекче дә, слесарь да, комбайнчы ярдәмчесе дә булдылар. Һәм менә Олег Романов, Сергей Яковлев, Сергей Борисов, Александр Катков һәм башкаларга кул сәгатьләре тапшырылды бу көнне.

Ә Иске Чаллы җирле үзидарә Советы рәисе Н.А.Борисова ул көнне шул авылдагы урта мәктәптә булды һәм шулай ук укучыларга рәхмәт әйтеп кыйммәтле бүләкләр өләште. Ындыр табагында тырышып эшләгән кызлар да бүләксез калмады.

Моннан тыш, ул иртәдә һәр укучы бизәкле стаканнарда йогурт белән сыйланды. Балаларның бу авыр заманда шушы кечкенә генә күчтәнәчкә дә ничек сөенүләрен әйтәсе дә юк. Бәйрәмнең бәйрәм. икәнлеген тойсыннар дип тырышты бит алар өчен зурлар.

**Н.ЛАЗАРЕВА.**

***Яңа Әлмәт урта мәктәбе.***

Шефлары - Нурлат автотранспорт предприятиесе вәкилләре килүе Белем бәйрәме ямен тагын да арттырып җибәрде. Берничә ел рәттән инде алар бу тантанага бик теләп киләләр. Быел предприятие директоры И.М.Вәлиев беренче класска барасы 24 укучыга бүләкләр тапшырды: мәктәп сумкасына тутырылган язу - сызу әсбаплары һәм 50шәр сум акча. Нәниләр йөзендәге шатлыкны күрсәгез иде сез!

"Татарстан" КХАсы рәисе Ә.Г. Саматов җәйге елларын хуҗалыкка булышып үткәргән укучыларга шулай ук истәлекле бүләкләр тапшырды. Мондый юмартлыктан гомуми тантана тагын да масштаблы төс алды. Белем көненең традицион чаралары - котлаулар һәм чыгышлар, күңелгә үтәрлек шигырьләр дә озак хәтердә калырлык булды.

**С.НУРУЛЛИНА.**


**Мамык урта мәктәбе.** Иртәнге сәгать 9.Укучылар үз классларына кереп парта артына утырдылар. Беренче дәрес - танышу чарасы - яңа укытучылар да бар, укучылар да. Аннан сәгать 10да тантаналы линейка башланды. Аны ачып, мәктәп директоры Р.Б.Шәмсетдинов укучылар һәм педагогларның җәйге чордагы эшләре һәм яңа уку елына бурычлар турында сөйләде. Тантанага килгән "Сөлчә" хуҗалыгы рәисе С.С.Фәхриев кыр эшләрендә хуҗалыкка булышкан укучыларга тыйнак кына булса да бүләкләр өләште. Аннан укыту бүлеге мөдире Т.Н.Фәткуллина узган уку елын "бишле"ләргә генә тәмамлаган укучыларга мактау кәгазьләре тапшырды. Тантана белән котларга җирле үзидарә Советы рәисе И.М.Крючков та килгән иде.

Кыңгырау чыңы озатуында балалар тагын классларга юнәлделәр. Яңа уку елы башланды. Белем иленә хәерле юл сезгә!

**А.КОСТИН.**

*Авыл яңарыш юлында*

# ДҮРТ КООПЕРАТИВНЫҢ ӨЧ ТАРИХЫ



сы, халыкны да авыр хәлдә калдырмыйсы, ничектер бер җиңел машина да юнәтәсе. Юкса, Анатолийга эшкә, мең төрле мәшәкать белән очраклы машинага утырып йөрергә туры килә. Әмма кичә йокымсыраган авылдашларының йөзендәге рухлану хисе аңа бетмәс -төкәнмәс көч бирә кебек. Шундый нәрсә икән ул - кооператив.

***

***Елаур якларыннан очып - канатланып кайттым. Андагы очрашулар, ниятләр - планнар, бәхәсләр - һәммәсе бу төбәкнең чынлап торып уянуы, үзе турында уйлап яши башлавының дәлиле иде, ләбаса! Дөрес, бәхәсле сораулар күп иде әле. Әйтик, җир паен кооперативка тапшырган эшләмәүчеләр белән мөнәсәбәт ничек булырга тиеш? Мартта алар барлык арендодательләргә 2шәр центнер ашлык бирергә килешенгән булганнар, дөресрәге, аларга шулай киңәш биргәннәр. Хәзер фикерләре үзгәрергә тора, ә кем белән киңәшергә? Һәр карарларын юридик нигезләп бирерлек бер белгеч булса икән районда, диләр. Тормыш кооперативларга шулай һәр көнне дистәләгән сорау куя. Проблемаларын "Агрохимсервис" хәл итешә, И.И.Мөхәммәтҗановның күп мәсьәләдә компетентлылыгы егетләргә иң кыен чакта да ярдәм итеп куя. Юкса, теге заманнарда Мәләкәстән алган запас частьләр өчен акча сорап авылдагыларны өркетеп бетергәннәр поставщиклар!***

***Шулай яши - яши килер ул осталык, тәҗрибә, иң мөһиме - теләк булсын. Ә әлегә кооперативлар берлеге яшәргә, үсәргә, киләчәк буыннарга үз төбәкләрен нык һәм төзек, перспективалы итеп тапшырырга зур теләк белән яши. Бу хакта район хакимияте башлыгының беренче урынбасары Ю.В.Терентьев та ассызыклап әйтте.***

***- Быел биредә зур уңыш ала алмадылар әле, әмма анда аларны гына гаепләп булмый. Халыкның эшкә кәефе, теләге бик зур, көзге эшләрне бик оешканлык белән алып баралар. Район җитәкчелеге төбәктә нәкъ менә шундый хуҗалык итү ысулы кирәк булганлыгына тагын бер кат инанды. Сайлаган курсны үзгәртергә җыенмыйбыз, кооперативларга мөстәкыйль эшләү мөмкинлеге бирелгән, җай булганда аларга ярдәм күрсәтелеп тора һәм торачак,- диде Юрий Владимирович.***

***Елаур шулай яңа тарихи борылыш чорында. Без аларда еш булырбыз әле. Әлегә беренче сөенечебез аларга юл башында хәер - фатиха булып ирешсен иде!***

***С.ХӘЙРУЛЛИНА.***

*"Петровский" кооперативы*

# «БЕЗ КЕМНӘН КИМ?»

"Петровский" кооперативында бер ай элек кенә җитәкче алыштырганнар. "Җитәкче булárак йомшак иде. Хәзергә кадәр расчет счетыбыз да юк әле безнең",- диләр. Башта Петровский, Сосновка халкы үзе дә элеккечә МСОга салынып брак яшәргә җыенган булган ахры. Аннан, тирә - күршеләрдә колач җәеп эшкә керешкәннәрен күргәч, кузгалырга мәҗбүр булалар. Җитәкче ясап Ефимов Анатолий Никоновичны сайлыйлар. Һәм яңача яшәү бирегә шулай ай - ай ярым элек кенә килә. Ике - Петровский һәм Сосновка авылларын берләштергән кооператив бердәм булып эшкә керешә: сенаж салалар, силос әзерлиләр, кышкылыкка печәннәре дә җитәчәк. 300 - 350 гектар уҗым чәчәргә булалар, анысын инде тәгәлләп киләләр иде.

Терлекчелектә дә хәрәкәт башлана. "Петровский" фермасына ремонт кирәклеге турында сүз чыккач, терлекчеләр инициативаны үз кулларына алалар: читтән кеше китермибез, үзебез ремонтлыйбыз дип килешәләр. Шулай итәләр дә. 4 терлекченең өчесе - ферма тирәләренә бер дигән итеп карда тота, ишек - идән - тәрәзәләр ремонтлый, берсе чиратлап көтүгә чыга.

Озак та үтми, җитәкче янына Сосновка фермасыннан делегация килә.

-Безгә дә ремонт кирәк бит. Ник һаман сузабыз? Әйдәгез, үзебез ремонт ясыйк.

Анатолий бик теләп ризалаша, билгеле.

"Петровский" шулай беренче адымнарын ясый. Җитәкче Ефимовның башында уйлар күп әле: расчет счеты ача-

*(Ахыры. Башы 98-99нчы саннарда).*



**Рәсемдә: "Нива" кооперативы комбайнчысы Петр Михайлович Журавлев ярдәмчесе Михаил Ижуков белән.**
**Н.АЗИЗОВ фотосы.**

# МӨҢГА ТАБЫНУ

**Тормышта шул юлны сайларга аңа әти - әниләре булышты. Һәм менә ничә ел инде шуның белән мавыга ул, күпсанлы шәкертләрен дә шул музыка дөньясына тарта...**



ШӘХСИ КАЛЕНДАРЬДА ИСТӘЛЕКЛЕ КӨН

Ул үскән гаиләдә барысы да музыкага табыналар. Әтисе дә кызының шушы юлдан китүен, музыка буенча һөнәри белем алуын тели. Ә 1973 нче елда Түбән Кама музыка училищесын тәмамлап, бу юлы инде укытучы буларак балалар музыка мәктәбенә килгәч, кыз каушап та кала: дәрес расписаниеләре бик тыгызлап тезелгән, чөнки класс бүлмәләре бары дүрт, мәктәп үзе дә Пионерлар йортында өйдәш кенә була... Ул вакыттан соң егерме биш ел узып киткән инде. Бихисап күп проблемаларны хәл итү турында баш ватып үткән ул еллар: дәресләр алып бару да, укуларның оештырылуына контрольлек итү дә, ата - аналар белән очрашып сөйләшүләр дә, зачетлар һәм имтиханнар кабул итү дә, чыгарылыш кичәләре, конкурслар һәм отчет концертлары оештыру, укучыларының беренче уңышларына сөенүләр, аларның уңышсызлыгына үзләреннән дә артык кайгырулар да күп була ул еллар эчендә. Болар һәммәсе балалар музыка мәктәбенең укыту эшләре бүлеге мөдире Люция Мөхтәр кызы Гыйззәтуллинаның гомер буе тугрылык саклаган эше. Шуңа да Нурлатта музыка мәктәбенең яңа бинасы, алай гына түгел, сәнгать сарае менә дигән булып өлгерүенә аннан да күп сөенүче аздыр да әле. Яңа бина турында бик бирелеп, дулкынлануын яшерә алмыйча сөйли Люция Мөхтәровна, аның киләчәген ничек күзаллавы турындагы уйларын да яшерми. Бирелдәге иркен класс бүлмәләре, гаять зур концерт залы, тынлы уен кораллары: кларнет, флейта, саксофон, гобой бүлегенә кабул итү бара да инде. Рәсем сәнгате классы ачалар - балалар үз хыялларындагы күренешләрне пумала белән кәгазь һәм башка материалга төшерергә дә өйрәнсеннәр. Бию классында идәнгә тиеп торган көзгеләр, балет станнары. Хор классларында да дәресләр дәвам итә. Башта, балаларны бу классска язганда ата - аналар каршы булганга, бу шөгыльнең балаларга файдалы булачагын озак төшендерергә, ә аена 15 сумның зур акча түгеллеген аңлатырга туры килә. Ә инде аларны беренче концертка чакыргач, ата - аналарның исләре китә: кара әле, балалары рәтен белеп җырларга да өйрәнгәннәр, оркестрында да уйный беләләр, тыңлау - тоемлау сизгерлекләре дә арткан бит, дип тел шартлаталар. Тоемлау дигәннән, Люция Мөхтәровна бу төшенчәгә гадәттәгедән зуррак һәм тирәнрәк мәгънә сала, укытучы эшендә сизгерлек һич тә ахыргы урында түгел дип саный: укучыларның берсен мактап җибәрү дә җитә, икенчесен мавыктырырга берәр җаен табарга кирәк була, өченчесенә, киресенчә, таләпне арттыру да комачау итми, ә инде дүртенчесе өчен чын мәгънәсендә көрәшергә кирәк була. Тагын шунысы: класска керер алдыннан үзеңнең шәхси проблемаларыңны да онытып, характер үзенчәлекләреңне дә калдырып торырга кирәк. Эшендә тәҗрибәле хезмәттәшләре Суфия Хөснулловна Сафина, Галина Владимировна Прокофьева, Розалия Идрисовна Гайнанова кебекләргә таяна ул. Гел аңлый, хәлеңә керә беләләр - ә тормышта бу аз нәрсә түгел. Хәзер аның янәшәсендә үзенең элеккеге укучылары да аз түгел инде. Быел менә Ләйсән Исхакова һәм Катя Шугаева Әлмәт музыка училищесы студентлары булдылар - Люция Мөхтәровна аларга ышанып ялгышмаган, димәк. Үз классында шөгыльләнүчеләрнең барысына да бер киңәш бирә ул: "Күбрәк тырышырга, үзеңдә түземлелек тәрбияләргә кирәк -шунсыз бернәрсә дә барып чыкмаячак.

... Кәефе төшеп китеп, аны ничек тә күтәрергә кирәк дип санаган чакларында "Айлы соната"ны уйный ул. Булыша, ди. Хәер, анысы гаҗәп тә түгел, музыка кешелек аңының иң нечкә бер чагылышы бит ул.

*Т.АЛЕКСЕЕВА.*
*Н.АЗИЗОВ фотосы.*

*Туган як тарихы*

# САГЫШТАН ТУГАН ИСЕМ

Киекле авылы табигатьнең гүзәл почмагына урнашкан. Ул әкияти сихри матур күлләр белән уратылган, өч инеше һәм авыл эчендә урнашкан ике зур күле булып, Чирмешәннең бормаланып - бормаланып тын гына аккан сул як ярына утырган. Киекле авылының исеме үзе үк бу тирәнең электән гаҗәеп бай табигатьле булуы хакында сөйли.

Исемнәр, атамалар... Киекленең һәр төбәгенең дә тарихи атамасы бар. Шулардан берсе - Толапый елгасы. Аның тарихы болайрак.

Киекле авылының түбән оч урамында Гайшә исемле кыз буй җитә. Тулган ай төсле ачык йөзле, кара кашлы, иңнәренә төшеп торган, өлгергән арыш кырыдай дулкын чәчле, ак каендай сылу Гайшә кызның гүзәллеге, уңганлыгы, сабырлыгы тирә -як авылларга да билгеле була. Кызның күзләре куе камышлар белән әйләндереп алынган саф сулы тирән зәңгәр күлдәй серле булган. Тирә - күрше авыллардан кызны сорап күп яучылар килә башлаган. Шушы ук авылда Мөхәммәди исемле уңган, җиде егетне берьюлы егарлык көчле, мәһабәт гәүдәле егет яшәгән. Кичке уеннарда Гайшә һәм Мөхәммәди күрешеп сөйләшә торган булганнар, мәңге бергә булырга вәгъдәләр бирешкәннәр. Ике якның да әти - әниләре яшьләрнең теләкләренә каршы килми, аларга хәер - фатыйха биреп туй иткәннәр. Болардай матур, бер - берсенә пар килгән тиңнәр бик сирәк була, дип халык алар бәхетенә сөенгән. Тик... Бәхет озын гомерле булмаган, аның сәгатьләре санаулы гына булган икән шул. Ил өстенә кара афәт иңгән, сугыш башланган. Гүзәл Гайшә үзенең җандай газиз ирен сугышка озаткан. Гайшә килен төшкән йорт Чирмешән кушылдыгы, язларын мул булып тулып, эссе җәйләрдә дә үзенең салкын сулы чишмәсеннән туенып, талгын саф сулы булып кала торган елга буена урнашкан. Ирен сугышка озаткач, Гайшә көн дә кичләрен йортлары янында елга ярында үскән ялгыз усак янына чыгып утырган, елга суларына карап сагышланып иреннән хәбәр көткән. Усакның яфраклары җилсез көнне дә акрын гына шыбырдашып, Гайшә белән серләшкәннәр, аның сагышын - сагынуын уртаклашканнар. Еллар үткән, көннәрдән бер көнне йортны кара кайгыга күмеп, Мөхәммәдинең сугышта үлүе турында хәбәр килгән. Күршедә Гали исемле малай үсеп килә икән. Ул Гайшәнең көн дә кичен усак янында ялгыз уйда, моң - сагышта утырганын күзәтә икән. Әнисеннән: - Нигә Гайшә апа көн дә кич шул агач янында елга суына карап утыра икән? - дип сорый. Әнисе аңа: - Әй улым, Гайшә апаң хәзер тол бит инде, үзенең хәсрәтен елгага сөйли торгандыр,- дигән. Шуннан соң малай Гайшәгә инде Гайшә апа дип түгел, ә "Толапай" дип дәшә башлаган. Гайшәнең иренә булган вәгъдәсе, тугрылыгы, мәхәббәте мәңгеләштерелә. Толапый атамасы телдән телгә күчеп, елгага исем булып кушылып кала.

# «БЕРЕБЕЗ ӨЧЕН БЕРЕБЕЗ КИРӘК»

22нче август көнне мәдәният йортына агылган халыкның иге - чиге юк иде. Бу киңәшмәгә Зирекле авылының урта мәктәбе укытучылары үзләренең отчет чыгышларын әзерләп килгән. Алып баручының мөлаем тавышыннан соң сәхнә пәрдәләре ашыкмый гына ике якка шуышты. Сәхнәдә - төсле телевизор, ә анда - видео язмада Зирекле урта мәктәбе. Аның матур бинасы, мул бакчалары. Талгын гына агылган җыр дулкынына ияреп туган авылыма, укыган мәктәбемә кайттым. Монда мин белем алдым, беренче эш көннәремне шунда башладым. Йөрәгемә тулган изге, кадерле хисләремне язып аңлатырлык түгел. Анда узган еллар минем өчен чиксез кадерле. Сәхнәгә бер - бер артлы укытучылар чыга. Монда минем коллегаларым гына түгел, монда миңа беренче хәреф өйрәткән остазларым. Йөрешләреннән, күз карашларыннан җылы нур бөркелгән газизләрем минем.

Фәридә Мөхлис кызы, Нәзимә Вахит кызы, Розалия Вәгыйзь кызы, Резедә Бари кызы, Наилә Гайнетдин кызы. Шул биш зат сабырлыгын җиһандагы нәрсә белән генә чагыштырыйм икән? Бик күп еллар узса да, алар минем юл күрсәтүчеләрем, күзем ачучыларым.

*"Беребез өчен беребез кирәк,*
*Бергә барыбер җиңелрәк.*
*Дөньялары ничек кенә,*
*Авыр булмасын".*

Фәридә Мөхлисовнаның йөрәкнең нечкә кылларын тибрәндергән моңлы тавышы залны тутыра. Әйе, дөньялар ничек кенә авыр булса да шундый матур яши, эшли бу яшь коллектив. - Монда яшьләр күп. Рузилә Әсхәт кызы, Әнисә Касыйм кызы, Зөлфәт Хәмит улы, Хәлим Рәфгат улы, Зөлфирә Рәшит кызы кебек яшьләр инде олы тәҗрибә туплап киләләр.

Бу мәктәптә директор урынбасары Гөлфания Мотыйгулла кызының тырышлыгы әйтеп бетергесез күп. Олы җанлы, мөлаем, сабыр холыклы бу укытучы бик зур олылау сүзләренә лаек. Ата - аналар, балалар бик сөя, ярата аны. Сәхнәдә җыр артыннан җыр агыла, дәрестән күренешләр күрсәтелә. Зиреклеләр бар уңганлыкларын күрсәттеләр. Мин аларның бер - берсенә булышып, тату гаилә кебек яшәүләренә күп еллар сокланып яшим. Дөрестән дә, аларның "берсе өчен берсе кирәк". Нинди генә авырлыклар килмәсен, мәктәп эшли, белем бирә, яши. Бу мәктәптән дәүләтебезгә лаеклы, тугры кешеләр генә чыгар. Моңа иманым камил минем. Аларга олы рәхмәт хисләремне юллыйм һәм эшләрендә зур уңышлар юлдаш булсын, дип телим.

*Лилия ДАУТОВА,*
*укытучы.*
*Нурлат шәһәре.*

# ИЗГЕ ЭШ БАШКАРДЫЛАР

Авылларның тарихы онытылмаска, киләчәк буыннар өчен дә югалмый сакланырга тиеш. Шушы максаттан чыгып, узган ел мәктәбебездә "Туган якны өйрәнү" түгәрәге оешты. Түгәрәкне мәктәпнең география укытучысы Роза Хәмидулловна Әһлиуллина җитәкләде. Укучылар түгәрәккә бик теләп йөрделәр һәм һәр төбәкнең тарихи атамаларын - исемнәрен ачыкладылар, шул урыннарга экскурсияләр оештырдылар. Авыл кешеләренең гореф - гадәтләрен, халык авыз иҗатын өйрәнделәр. Авылның үткәне, колхоз оешу тарихы турындагы материалларны тупландырдылар. Шулай итеп, алар бик зур, кирәкле һәм изге эш башкардылар.

*Р.МӘСЛӘХОВА.*
*Киекле авылы.*

